ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 май 2019ел № 2479

Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – административ регламент) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып

чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р. Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 15 маендагы
2479 нчы карарына
кушымта

Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – идарә).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Идарәнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 239 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе-җомга 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
шимбә, якшәмбе: ял көннәре;
төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

Идарәнең белешмә телефоннары: 30-55-08, 30-58-09, 30-58-12, 30-58-14.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты адресы: (http://www.nabchelny.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт, шулай ук идарәнең урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.10 пунктларында (пунктчаларында) күрсәтелгән муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматларны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) аша;

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша;

5) Башкарма комитетта (идарәдә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта – gradoctroitel@mail.ru аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат идарә белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәтне күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба - РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), ст. 16 );

2) Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, ст. 4147);

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179);

5) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 11.04.2011, №15, ст. 2036);

6) «Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 20.11.1995, №47, ст. 4473);

7) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 нчы карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 11.04.2016, №15, ст. 2084);

8) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәкле белдерү кәгазе формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр санлы приказы (алга таба – РФ Төзелеш министрлыгы приказы) (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://pravo.gov.ru, 28.09.2018);

9) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ санлы Закон) (Республика Татарстан, №155-156, 03.08.2004);

10) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005; №249-250, 30.12.2005);

11) Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

12) Башкарма комитетның 2012 елның 24 маендагы 372 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Идарә турында нигезнамә);

13) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

14) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гариза бирүче – физик яки юридик зат (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) яисә аларның телдән, язма яки электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос белән идарәгә мөрәҗәгать иткән вәкаләтле вәкиле;

төзүче – үзенә караган җир участогында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны, шулай ук инженерлык тикшеренүләрен башкаруны, әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик яки юридик зат;

техник заказчы – төзүче тарафыннан вәкаләтләнгән һәм төзүче исеменнән инженерлык тикшеренүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау турында килешүләр төзи, әлеге эш төрләрен башкаруга йөкләмәләр әзерли; инженерлык тикшеренүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүне, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыручы затларга күрсәтелгән эш төрләрен башкару өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра, проект документларын раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, РФ Шәһәр төзелеше кодексында каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра торган юридик зат яки профессиональ нигездә эш итүче физик зат. Төзүче техник заказчы функцияләрен мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга хокуклы;

техник хата – Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза дигәндә планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе (1 нче кушымта) аңлашыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсе; Муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе йөзендә Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсе;<br>210-ФЗ санлы<br>Федераль закон;<br>Шәһәр Уставы;<br>Идарә турында нигезнамә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1) Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү турында белдерү кәгазе (2 нче кушымта);<br>2) Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында белдерү кәгазе (3 нче кушымта)<br>Белдерү кәгазенең формалары РФ Төзелеш министрлыгы Приказы белән расланган | РФ Шәһәр төзелеше кодексының<br>51.1 маддәсенең<br>7, 8 бүлекләре |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | 1) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында белдерү кәгазе кергән көннән башлап җиде эш көне эчендә – индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү объекты параметрларының туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү;<br>2) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында белдерү кәгазе кергән көннән башлап 20 эш көне эчендә – индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү объекты параметрларының туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү (индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган һәм планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә типовой архитектура чишелешенә күрсәтмә булмаган очракта) | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсенең 7, 8 бүлекләре |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) РФ Төзелеш министрлыгы Приказы белән расланган форма буенча индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында белдерү кәгазе (алга таба – планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе) (1 нче кушымта);<br>2) планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе төзүченең вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>3) чит ил юридик заты төзүче булып торган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе;<br>4) индивидуаль торак төзелеше объектын (алга таба – ИТТ объекты) яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсенең 1, 3, 5, 14 бүлекләре |

| | | |
|---|---|---|
| | очракта, ИТТ объектының яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирлама (алга таба – объектның тышкы күренешенә тасвирлама). Объектның тышкы күренешенә тасвирлама үз эченә түбәндәгеләрне ала:<br>1) текст рәвешендә тасвирлау:<br>- ИТТ объекты яки бакча йорты параметрларына күрсәтмә;<br>- ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешенең төсләр чишелеше;<br>- ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешен билгели торган һәм файдалану өчен планлаштырылган төзелеш материаллары;<br>- капиталь төзелеш объектының архитектура чишелешләренә таләпләр буларак шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән ИТТ объектының яки бакча йортының башка характеристикаларының тасвирламасы;<br>2) график тасвирлама (ИТТ объекты яки бакча йорты фасадын һәм конфигурациясен кертеп, ИТТ объектының яки бакча йортының тышкы күренешенең сурәте).<br>«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә расланган капиталь төзелеш объектының типовой архитектура чишелеше нигезендә, гариза бирүче федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә ИТТ объекты яки бакча йорты төзүне яки реконструкцияләүне планлаштырган очракта, планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазенә ИТТ объектының яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламаны теркәү таләп ителми. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә шундый типовой архитектура чишелешенә күрсәтелә.<br>ИТТ объектын яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү параметрлары үзгәргән очракта:<br>1) РФ Төзелеш министрлыгы Приказы белән расланган форма буенча ИТТ объектын яисә бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында белдерү кәгазе (алга таба – параметрларны үзгәртү турында белдерү кәгазе) (4 нче кушымта); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) параметрларны үзгәртү турында белдерү кәгазе төзүченең вәкиле тарафыннан җибәрелгән очракта, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>3) чит ил юридик заты төзүче булып торган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе;<br>4) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган очракта, ИТТ объектының яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирлама | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Җир участогына хокуклар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, аңа хокук билгеләүче документлар.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда күрсәтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документлар тапшырылмау, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигез булып тормый | РФ Шәһәр төзелеше кодексының<br>51.1 маддәсенең 4 бүлеге |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү (муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган дәүләт | Килешенү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документлар тиеш булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә һәм белдерү кәгазенә теркәлгән документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган җитди бозулар;<br>3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;<br>4) планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән мәгълүматлар яисә регламентның 2.5 пунктында каралган документлар булмау. Бу очракта, планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән көннән башлап өч эш көне эчендә әлеге белдерү кәгазе һәм аңа теркәлә торган документлар каралмыйча, кире кайтарылу сәбәпләрен күрсәтеп, гариза бирүчегә кире кайтарыла. Бу очракта планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе җибәрелмәгән дип санала. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсенең 6 бүлеге |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр:<br>1) планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яисә бакча йорты параметрлары Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына яки РФ Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән һәм планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата таләпләргә туры килмәү; | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 маддәсенең 10 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнарында билгеләнгән һәм планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре һәм (яки) чикләүләр нигезендә, планлаштырылган төзү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителми;<br>3) планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе, җир участогына хокуклары булмау сәбәпле төзүче булып исәпләнмәгән зат тарафыннан бирелү яки җибәрелү;<br>4) мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органыннан индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламаның тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше Регламентында билгеләнгән архитектура чишелешләре таләпләренә туры килмәве турында белдерү кәгазе керү. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләүне исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, әлеге түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | 210-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсенең 10 пункты |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүченең запросын теркәү срогы | Планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазе кергән көннән башлап бер көн эчендә. Запрос электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән очракта, ул ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | Эш регламенты |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тотыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен дә истә тотып урнаштырыла. | 210-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсенең 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм бирү бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында(http://www.nabchelny.ru),, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>белдерү кәгазен һәм аңа теркәлгәнган документларны кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк) муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә консультация бирүне, белдерү кәгазен кабул итүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша алырга мөмкин. Законда муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы белдерү кәгазен электрон рәвештә бирү каралган очракта, белдерү кәгазе Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Планлаштырылган төзелеш турында белдерү кәгазен шәхсән биргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы регламентка 6 нчы кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен идарәгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда белдерү кәгазе бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

### Планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү

3.3. Белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша яки КФҮ аша, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, ИТТ объектын яки бакча йортын планлаштырылган *төзү яки* реконструкцияләү турында белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе) бирә һәм Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.2. Белдерү кәгазен шәхсән биргәндә эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен билгели;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч кәгазе буенча эш иткәндә).

Кимчелекләр булмаган очракта эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

белдерү кәгазен кабул итә һәм махсус журналда терки;

документларны кабул итү датасы, керү номеры, дата турында билге куеп, гариза бирүчегә белдерү кәгазенең күчермәсен бирә;

белдерү кәгазен һәм теркәлгән документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә белдерү кәгазен теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

белдерү кәгазен һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

белдерү кәгазен теркәү – белдерү кәгазе кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитит Җитәкчесенә җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе белдерү кәгазен һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен «Электрон документлар әйләнеше» системасы (алга таба – ЭДӘ) аша Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына (алга таба – идарә башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура белдерү кәгазе теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карап тикшерелгән һәм идарә башлыгына җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар.

3.3.4. Идарә башлыгы тапшырылган белдерү кәгазен, документларны карап тикшерә һәм аларны ЭДӘ аша башкаручыга – идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура белдерү кәгәзе теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә белгеченә җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Идарә белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) аша электрон рәвештә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүматлар булган) өземтә бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура идарә белгеченә документлар кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ВЭХС аша җибәрелгән запрос.

3.4.2. ВЭХС аша кергән запрос нигезендә мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе (алга таба – кире кагу турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура документлар (мәгълүмат) бирү турында запрос кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәгә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яисә кире кагу турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәен әзерләү

3.5.1. Кабул ителгән документлар нигезендә идарә белгече:

1) белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яки бакча йорты параметрларының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларына һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата таләпләргә туры килүен, шулай ук РФ җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм чикләүләр нигезендә ИТТ объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителүне тикшерә;

2) белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яисә бакча йорты параметрларының туры килүе турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – туры килү турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

3) регламентның 2.9 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яисә бакча йорты параметрларының туры килмәве турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

4) идарә башлыгына туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: идарә башлыгына җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.2. Идарә башлыгы туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килешенә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә башлыгына белдерү кәгазе кергән көнне имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.3. Башкарма комитет Җитәкчесе туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын раслый, имзалый, аны Башкарма комитет мөһере белән раслый һәм идарә белгеченә җибәрә.

Туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын раслау процедурасы алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалаланган, мөһер белән расланган һәм идарә белгеченә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе проекты яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проекты.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Идарә белгече:

1) туры килү турында белдерү кәгазе проектын яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе проектын терки;

2) төзүче тарафыннан белдерү кәгазендә билгеләнгән ысул белән аңа туры килү турында белдерү кәгазен яисә туры килмәү турында белдерү кәгазен җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан документлар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: төзүчегә җибәрелгән туры килү турында белдерү кәгазе яисә туры килмәү турында белдерү кәгазе.

### Планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кәгазендә (анының нигезендә ИТТ объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла) типовой архитектура чишелешенә күрсәтмә булмаган очракта, планлаштырылган төзелеш яки реконструкцияләү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү

3.7. Белдерү кәгазен кабул итү һәм теркәү

1.7.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат яки КФҮ аша, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә ИТТ яки бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе) бирә һәм регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.7.2. Белдерү кәгазен шәхсән биргәндә эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен билгели;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч кәгазе буенча эш иткәндә).

Кимчелекләр булмаган очракта эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

белдерү кәгазен кабул итә һәм махсус журналда терки;

документларны кабул итү датасы, керү номеры, дата турында билге куеп, гариза бирүчегә белдерү кәгазенең күчермәсен бирә;

белдерү кәгазен һәм теркәлгән документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә белдерү кәгазен теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

белдерү кәгазен һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

белдерү кәгазен теркәү – белдерү кәгазе кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитит Җитәкчесенә җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.7.3. Башкарма комитет Җитәкчесе белдерү кәгазен һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен ЭДӘ аша идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура ЭДӘ аша документларны кабул иткән көннән башлап бер эш көненнән дә соңармаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карап тикшерелгән һәм идарә башлыгына җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар.

3.7.4. Идарә башлыгы тапшырылган белдерү кәгазен, документларны карап тикшерә һәм аларны ЭДӘ аша башкаручыга – идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура белдерү кәгәзе теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә белгеченә җибәрелгән белдерү кәгазе һәм документлар.

3.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү

3.8.1. Идарә белгече ВЭХС аша электрон рәвештә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүматлар булган) өземтә бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура идарә белгеченә документлар кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ВЭХС аша җибәрелгән запрос.

3.8.2. ВЭХС аша кергән запрос нигезендә мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазе (алга таба – кире кагу турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура документлар (мәгълүмат) бирү турында запрос кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәгә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яисә кире кагу турында белдерү кәгазе.

3.8.3. Идарә белгече алынган документлар нигезендә, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, белдерү кәгазен һәм аңа теркәлгән ИТТ объекты яисә бакча йортының тышкы күренешенә тасвирлама мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына (алга таба – ТР башкарма хакимияте органы) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура белдерү кәгазе кергән көннән башлап өч эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ТР башкарма хакимияте органына җибәрелгән белдерү кәгазе һәм аңа теркәлгән ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирлама.

3.8.4. ТР башкарма хакимияте органы ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламаны карап тикшерә, ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламаның тарихи җирлекне саклау предметына һәм федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләре таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында белдерү кәгазе (туры килү яки туры килмәү турында белдерү кәгазе) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура ИТТ  яисә бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламасы булган белдерү кәгазе кергән көннән башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәгә җибәрелгән туры килү яки туры килмәү турында белдерү кәгазе.

Күрсәтелгән срокта туры килмәү турында белдерү кәгазе җибәрелмәгән очракта, ИТТ объекты яки бакча йортының тышкы күренешенә тасвирламаның тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә карата таләпләргә туры килә дип санала.

3.9. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.9.1. Алынган туры килү яки туры килмәү турында белдерү кәгазе нигезендә

идарә белгече:

1) белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яки бакча йорты параметрларының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзүнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларына һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән һәм белдерү кәгазе кергән датага гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүен, шулай ук, Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм белдерү кәгазе кергән көнгә гамәлдә булган җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм чикләүләр нигезендә ИТТ объектын яки бакча йорты урнаштыру рөхсәт ителүне тикшерә;

2) белдерү кәгазендә күрсәтелгән ИТТ объекты яисә бакча йорты параметрларының туры килүе турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – туры килү турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

